| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

___14.10.2024________ Казан ш. №___222-ОД________

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Энергия ресурсларының нәтиҗәле технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2023 елның 18 декабрендәге 265-ОД номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы карарына үзгәреш кертү турында» 2024 елның 20 февралендәге 190 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 11 сентябрендәге 1117 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итүнең цифрлы модулендә «Татарстан Республикасын икътисадый үстерү һәм инновацион икътисад» дәүләт программасы структурасына керә торган «Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру» региональ проекты паспортын актуальләштерү нигезендә

**боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Энергия ресурсларының нәтиҗәле технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2023 елның 18 декабрендәге 265-ОД номерлы боерыгына (алга таба – Боерык) (Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2024 елның 16 маендагы 89-ОД

номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы дәүләт һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгеләүгә вәкаләтле башкарма органнары турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 28 февралендәге 178 номерлы карары белән» сүзләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгеләүгә вәкаләтле республика башкарма хакимият органнары турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 28 февралендәге 178 номерлы карары белән» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Боерык белән расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Энергия ресурсларының нәтиҗәле технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр күләмен һәм бирү шартларын билгеләү тәртибенең (алга таба – Тәртип) 15 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия бирү нәтиҗәсенең һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараның тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларның нәтиҗәләренә ирешү мониторингы Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә уздырыла.»;

Тәртипкә карата 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге Боерыкның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Юридик бүлеккә боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

4. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрының беренче урынбасары Р.М.Карповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр О.В.Коробченко

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2023 елның 18 декабрендәге 265-ОД номерлы боерыгы белән расланган, аңа карата Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасының Энергия ресурслары нәтиҗәлелеге технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә башка максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә 1 нче кушымта

**Нәтиҗәләрнең кыйммәтләре**
**(соңгы нәтиҗәләрне бәяләү күрсәткечләре)**

| т/с | Региональ проект күрсәткечләре | Үлчәү берәмлеге (ОКЕИ буенча) | База әһәмияте | | Вакыты, ел | | | Арту билгесе/кимү |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | билгесе | ел | 2025 | 2026 | 2027 | |
| 1 | Предприятиеләргә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча каралган ярдәм чаралары турында хәбәр ителгән | шартлы берәмлек | 300 | 2024 | 300 | 300 | 300 | арта баручы |
| 2 | Предприятиеләрнең нәтиҗәлелеген арттыру темасына семинарлар, утырышлар, түгәрәк өстәлләр уздырылган | шартлы берәмлек | 1 | 2024 | 2 | 2 | 2 | арта баручы |
| 3 | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру мәсьәләсе буенча уздырылган киңәшмәләр | шартлы берәмлек | 8 | 2024 | 5 | 5 | 5 | арта баручы |
| 4 | ppt.tatarstan.ru сайтына керү тәэмин ителгән | мең данә | 30 | 2024 | 30 | 30 | 30 | арта баручы |
| 5 | С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводы – «Туполев» гавами акционерлык җәмгыяте филиалында хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча проектлар тормышка ашырылган | шартлы берәмлек | 2 | 2024 | 2 | 2 | 2 | арта баручы |
| 6 | Студентларны сакчыл җитештерү ысулларына өйрәтү өлешендә югары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары белән хезмәттәшлек кысаларында «җитештерү һәм офис процесслары фабрикасы» уку мәйданчыгында укыту | шартлы берәмлек | 0 | 2024 | 5 | 5 | 5 | арта баручы |

| т/с | Региональ проект күрсәткечләре | Үлчәү берәмлеге (ОКЕИ буенча) | База әһәмияте | | Вакыты, ел | | | Арту билгесе/кимү |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | билгесе | ел | 2025 | 2026 | 2027 | |
| | чаралары уздырылды | | | | | | | |
| 7 | Студентларны сакчыл җитештерү ысулларына өйрәтү өлешендә югары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары белән хезмәттәшлек кысаларында сакчыл җитештерү инструментлары буенча укыту тренинглары үткәрелде | шартлы берәмлек | 0 | 2024 | 50 | 50 | 50 | арта баручы |
| 8 | Студентларны сакчыл җитештерү ысулларына өйрәтү өлешендә югары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары белән хезмәттәшлек кысаларында модель предприятиеләргә экскурсияләр уздырылды | шартлы берәмлек | 0 | 2024 | 3 | 3 | 3 | арта баручы |
| 9 | Матбугат турлары уздырылды | шартлы берәмлек | 0 | 2024 | 1 | 1 | 1 | арта баручы |
| 10 | Социаль пабликаларда басмалар тәэмин ителде | шартлы берәмлек | 0 | 2024 | 180 | 180 | 180 | арта баручы |
| 11 | Кече предприятиеләргә адреслы ярдәм күрсәтелде | шартлы берәмлек | 0 | 2024 | 5 | 5 | 5 | арта баручы |
| 12 | Татарстан Республикасы предприятиеләрендә бизнес-процессларны автоматлаштыру дәрәҗәсен диагностикалау һәм бәяләү буенча проектлар гамәлгә ашырылды | шартлы берәмлек | 0 | 2024 | 5 | 5 | 5 | арта баручы |
| 13 | Татарстан Республикасы предприятиеләрендә сакчыл җитештерүне гамәлгә кертү буенча «Хезмәт җитештерүчәнлеге» федераль проекты критерийларына туры килми торган пилот проектлар гамәлгә ашырылды | шартлы берәмлек | 0 | 2024 | 10 | 10 | 10 | арта баручы |